ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Россия Федерациясе субъектлары – Татарстан Республикасы һәм Ульяновск өлкәсе арасындагы чик урнашкан урынны билгеләү турында 2022 елның 4 октябрендәге 52/10-Д номерлы килешүне раслау хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Россия Федерациясе субъектлары – Татарстан Республикасы һәм Ульяновск өлкәсе арасындагы чик урнашкан урынны билгеләү турында 2022 елның 4 октябрендәге 52/10-Д номерлы килешүне әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 20 октябре
№ 1646-VI ДС

# РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ СУБЪЕКТЛАРЫ – ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҺӘМ УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕ АРАСЫНДАГЫ ЧИК УРНАШКАН УРЫННЫ БИЛГЕЛӘҮ ТУРЫНДА КИЛЕШҮ

2022 елның 4 октябре

Татарстан Республикасы исеменнән Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Президенты Миңнеханов Рөстәм Нургали улы, бер яктан, һәм Ульяновск өлкәсе исеменнән Ульяновск өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең 2005 елның 19 маендагы 31/311 номерлы карары нигезендә кабул ителгән Ульяновск өлкәсе Уставы нигезендә эш итүче Ульяновск өлкәсе Губернаторы Русских Алексей Юрьевич, икенче яктан, алга таба «Яклар» дип аталачак, Татарстан Республикасы Конституциясенә, «Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше турында» 2005 елның 7 декабрендәге 116-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Ульяновск өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең 2005 елның 19 маендагы 31/311 номерлы карары нигезендә кабул ителгән Ульяновск өлкәсе Уставына, «Ульяновск өлкәсенең административ-территориаль төзелеше турында» 2006 елның 3 октябрендәге 126-ЗО номерлы Ульяновск өлкәсе Законына нигезләнеп, түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеде.

1 статья

Россия Федерациясе субъектлары – Татарстан Республикасы һәм Ульяновск өлкәсе арасындагы чик урнашкан урынны әлеге Килешүгә 1 нче кушымтада каралган Россия Федерациясе субъектлары – Татарстан Республикасы һәм Ульяновск өлкәсе арасындагы чикнең график тасвирламасы һәм әлеге Килешүгә 2 нче кушымтада каралган Россия Федерациясе субъектлары – Татарстан Республикасы һәм Ульяновск өлкәсе арасындагы чикнең текстлы тасвирламасы нигезендә билгеләнде дип санарга.

Россия Федерациясе субъектлары – Татарстан Республикасы һәм Ульяновск өлкәсе арасындагы чикнең координаталы тасвирламасы, әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып торган чикнең график һәм текстлы тасвирламасына нигезләнеп, Россия Федерациясе законнары нигезендә башкарыла. Күрсәтелгән чикнең координаталы тасвирламасы Якларның вәкаләтле органнары тарафыннан килештерелә.

2 статья

Россия Федерациясе субъектлары – Татарстан Республикасы һәм Ульяновск өлкәсе арасындагы чик әлеге Килешү төзелү нәтиҗәсендә үзгәрми, күрсәтелгән чикнең урнашкан урыны һәм узуы тасвирламасы мәсьәләләре буенча фикер каршылыклары юк.

3 статья

Әлеге Килешү Якларның дәүләт хакимияте законнар чыгару (вәкиллекле) органнары тарафыннан аның раслануы турында хокукый актлары үз көченә кергән көннән үз көченә керә.

4 статья

Әлеге Килешүгә Яклар тарафыннан өстәмә килешүләр төзелү юлы белән үзгәрешләр кертелергә мөмкин.

5 статья

Әлеге Килешү бер үк төрле юридик көчкә ия дүрт нөсхәдә төзелде. Һәр Якта әлеге Килешүнең бер нөсхәсе бар, өченче һәм дүртенче нөсхәләр тиешенчә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Ульяновск өлкәсенең Закон чыгару Собраниесенә тапшырыла.


| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы өчен | Ульяновск өлкәсе өчен |
| Татарстан Республикасы Президенты | Ульяновск өлкәсе Губернаторы |
| _______________ Р.Н. Миңнеханов | _______________ А.Ю. Русских |
| М.У. | М.У. |

Россия Федерациясе субъектлары –
Татарстан Республикасы һәм
Ульяновск өлкәсе арасындагы
чик урнашкан урынны билгеләү турында
2022 елның 4 октябрендәге 52/10-Д номерлы
килешүгә
1 нче кушымта

# РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ СУБЪЕКТЛАРЫ – ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҺӘМ УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕ АРАСЫНДАГЫ ЧИКНЕҢ ГРАФИК ТАСВИРЛАМАСЫ

**Графическое описание границы между субъектами Российской Федерации – Республикой Татарстан и Ульяновской областью**

Обзорная схема границ




**Масштаб 1:500 000**


Используемые условные знаки и обозначения:

- – граница между Республикой Татарстан и Ульяновской областью
- – граница между субъектами Российской Федерации
- – граница муниципального района, городского округа

## Графическое описание границы между субъектами Российской Федерации – Республикой Татарстан и Ульяновской областью



Лист 1




**Масштаб 1:25 000**


Используемые условные знаки и обозначения:

- 1 – поворотная точка границы
- – граница между Республикой Татарстан и Ульяновской областью
- *I* – номер лесного квартала
- – граница между субъектами Российской Федерации по данным картографической основы*

*Цифровые топографические карты открытого пользования ФГБУ «Центр геодезии, картографии и ИПД» М 1:25 000, 2016 г.

**Графическое описание границы между субъектами Российской Федерации – Республикой Татарстан и Ульяновской областью**

Лист 2




**Масштаб 1:25 000**

Используемые условные знаки и обозначения:

● 4 – поворотная точка границы

– граница между Республикой Татарстан и Ульяновской областью

*53* – номер лесного квартала


– граница между субъектами Российской Федерации по данным картографической основы*

– граница поселения

*Цифровые топографические карты открытого пользования ФГБУ «Центр геодезии, картографии и ИПД» М 1:25 000, 2016 г.

**Графическое описание границы между субъектами Российской Федерации – Республикой Татарстан и Ульяновской областью**

Лист 3




**Масштаб 1:25 000**

Используемые условные знаки и обозначения:

● **7** – поворотная точка границы

——— – граница между Республикой Татарстан и Ульяновской областью


—·—·— – граница между субъектами Российской Федерации по данным картографической основы*

*Цифровые топографические карты открытого пользования ФГБУ «Центр геодезии, картографии и ИПД» М 1:25 000, 2016 г.

**Графическое описание границы между субъектами Российской Федерации – Республикой Татарстан и Ульяновской областью**



Лист 4




**Масштаб 1:25 000**

Используемые условные знаки и обозначения:

● 7 – поворотная точка границы


– граница между Республикой Татарстан и Ульяновской областью

– граница между субъектами Российской Федерации по данным картографической основы*

*Цифровые топографические карты открытого пользования ФГБУ «Центр геодезии, картографии и ИПД» М 1:25 000, 2016 г.

**Графическое описание границы между субъектами Российской Федерации – Республикой Татарстан и Ульяновской областью**

Лист 5




**Масштаб 1:25 000**


Используемые условные знаки и обозначения:

- ● 9 – поворотная точка границы
- – граница между Республикой Татарстан и Ульяновской областью
- – граница между субъектами Российской Федерации по данным картографической основы*
- – граница муниципального района
- – граница поселения

*Цифровые топографические карты открытого пользования ФГБУ «Центр геодезии, картографии и ИПД» М 1:25 000, 2016 г.

**Графическое описание границы между субъектами Российской Федерации –
Республикой Татарстан и Ульяновской областью**

Лист 6




**Масштаб 1:25 000**


Используемые условные знаки и обозначения:

- ● **11** – поворотная точка границы
- ——— – граница между Республикой Татарстан и Ульяновской областью
- *44* – номер лесного квартала
- —·—·— – граница между субъектами Российской Федерации по данным картографической основы*
- ——— – граница поселения

*Цифровые топографические карты открытого пользования ФГБУ «Центр геодезии, картографии и ИПД» М 1:25 000, 2016 г.

**Графическое описание границы между субъектами Российской Федерации – Республикой Татарстан и Ульяновской областью**

Лист 7




**Масштаб 1:25 000**


Используемые условные знаки и обозначения:

- ● **15** – поворотная точка границы
- – граница между Республикой Татарстан и Ульяновской областью
- *109* – номер лесного квартала
- – граница между субъектами Российской Федерации по данным картографической основы*
- – граница муниципального района
- – граница поселения

*Цифровые топографические карты открытого пользования ФГБУ «Центр геодезии, картографии и ИПД» М 1:25 000, 2016 г.

# Графическое описание границы между субъектами Российской Федерации – Республикой Татарстан и Ульяновской областью

Лист 8




**Масштаб 1:25 000**

Используемые условные знаки и обозначения:


- 17 – поворотная точка границы
- – граница между Республикой Татарстан и Ульяновской областью
- – граница между субъектами Российской Федерации по данным картографической основы*
- – граница поселения

*Цифровые топографические карты открытого пользования ФГБУ «Центр геодезии, картографии и ИПД» М 1:25 000, 2016 г.

**Графическое описание границы между субъектами Российской Федерации – Республикой Татарстан и Ульяновской областью**



Лист 9




**Масштаб 1:25 000**

Используемые условные знаки и обозначения:


- 18 – поворотная точка границы
- – граница между Республикой Татарстан и Ульяновской областью
- – граница между субъектами Российской Федерации по данным картографической основы*
- – граница поселения

*Цифровые топографические карты открытого пользования ФГБУ «Центр геодезии, картографии и ИПД» М 1:25 000, 2016 г.

## Графическое описание границы между субъектами Российской Федерации – Республикой Татарстан и Ульяновской областью



Лист 10




**Масштаб 1:25 000**


Используемые условные знаки и обозначения:

- 19 – поворотная точка границы
- – граница между Республикой Татарстан и Ульяновской областью
- – граница между субъектами Российской Федерации по данным картографической основы*
- – граница поселения

*Цифровые топографические карты открытого пользования ФГБУ «Центр геодезии, картографии и ИПД» М 1:25 000, 2016 г.

**Графическое описание границы между субъектами Российской Федерации – Республикой Татарстан и Ульяновской областью**

Лист 11




**Масштаб 1:25 000**


Используемые условные знаки и обозначения:

- ● 21 – поворотная точка границы
- ——— – граница между Республикой Татарстан и Ульяновской областью
- –·–·– – граница между субъектами Российской Федерации по данным картографической основы*
- ——— – граница поселения

*Цифровые топографические карты открытого пользования ФГБУ «Центр геодезии, картографии и ИПД» М 1:25 000, 2016 г.

**Графическое описание границы между субъектами Российской Федерации – Республикой Татарстан и Ульяновской областью**

Лист 12




**Масштаб 1:25 000**

Используемые условные знаки и обозначения:

● 24 – поворотная точка границы

– граница между Республикой Татарстан и Ульяновской областью


– граница между субъектами Российской Федерации по данным картографической основы*

*Цифровые топографические карты открытого пользования ФГБУ «Центр геодезии, картографии и ИПД» М 1:25 000, 2016 г.

**Графическое описание границы между субъектами Российской Федерации – Республикой Татарстан и Ульяновской областью**



Лист 13




**Масштаб 1:25 000**

Используемые условные знаки и обозначения:


- ● 26 – поворотная точка границы
- ——— – граница между Республикой Татарстан и Ульяновской областью
- —·—·— – граница между субъектами Российской Федерации по данным картографической основы*
- ——— – граница поселения

*Цифровые топографические карты открытого пользования ФГБУ «Центр геодезии, картографии и ИПД» М 1:25 000, 2016 г.

**Графическое описание границы между субъектами Российской Федерации – Республикой Татарстан и Ульяновской областью**



Лист 14




**Масштаб 1:25 000**

Используемые условные знаки и обозначения:

● 29 – поворотная точка границы

– граница между Республикой Татарстан и Ульяновской областью


– граница между субъектами Российской Федерации по данным картографической основы*

– граница поселения

*Цифровые топографические карты открытого пользования ФГБУ «Центр геодезии, картографии и ИПД» М 1:25 000, 2016 г.

**Графическое описание границы между субъектами Российской Федерации – Республикой Татарстан и Ульяновской областью**

Лист 15




**Масштаб 1:25 000**


Используемые условные знаки и обозначения:

- ● 31 – поворотная точка границы
- (красная линия) – граница между Республикой Татарстан и Ульяновской областью
- — · · — · · – граница между субъектами Российской Федерации по данным картографической основы*
- (фиолетовая линия) – граница поселения

*Цифровые топографические карты открытого пользования ФГБУ «Центр геодезии, картографии и ИПД» М 1:25 000, 2016 г.

**Графическое описание границы между субъектами Российской Федерации – Республикой Татарстан и Ульяновской областью**

Лист 16




**Масштаб 1:25 000**


Используемые условные знаки и обозначения:

- 33 – поворотная точка границы
- – граница между Республикой Татарстан и Ульяновской областью
- – граница между субъектами Российской Федерации по данным картографической основы*
- – граница муниципального района
- – граница поселения

*Цифровые топографические карты открытого пользования ФГБУ «Центр геодезии, картографии и ИПД» М 1:25 000, 2016 г.

**Графическое описание границы между субъектами Российской Федерации – Республикой Татарстан и Ульяновской областью**

Лист 17




**Масштаб 1:25 000**


Используемые условные знаки и обозначения:

- ● 35 – поворотная точка границы
- ——— – граница между Республикой Татарстан и Ульяновской областью
- —·· — ·· – граница между субъектами Российской Федерации по данным картографической основы*
- — · — · – граница муниципального района

*Цифровые топографические карты открытого пользования ФГБУ «Центр геодезии, картографии и ИПД» М 1:25 000, 2016 г.

**Графическое описание границы между субъектами Российской Федерации – Республикой Татарстан и Ульяновской областью**

Лист 18




**Масштаб 1:25 000**


Используемые условные знаки и обозначения:

- 37 – поворотная точка границы
- – граница между Республикой Татарстан и Ульяновской областью
- – граница между субъектами Российской Федерации по данным картографической основы*
- – граница муниципального района

*Цифровые топографические карты открытого пользования ФГБУ «Центр геодезии, картографии и ИПД» М 1:25 000, 2016 г.

**Графическое описание границы между субъектами Российской Федерации – Республикой Татарстан и Ульяновской областью**

Лист 19




**Масштаб 1:25 000**


Используемые условные знаки и обозначения:

- ● 41 – поворотная точка границы
- – граница между Республикой Татарстан и Ульяновской областью
- *I* – номер лесного квартала
- – граница между субъектами Российской Федерации по данным картографической основы*
- – граница муниципального района

*Цифровые топографические карты открытого пользования ФГБУ «Центр геодезии, картографии и ИПД» М 1:25 000, 2016 г.

**Графическое описание границы между субъектами Российской Федерации – Республикой Татарстан и Ульяновской областью**

Лист 20




**Масштаб 1:100 000**


Используемые условные знаки и обозначения:

- 42 – поворотная точка границы
- – граница между Республикой Татарстан и Ульяновской областью
- 62 – номер лесного квартала
- – граница между субъектами Российской Федерации по данным картографической основы*
- – граница муниципального района
- – граница поселения

*Цифровые топографические карты открытого пользования ФГБУ «Центр геодезии, картографии и ИПД» М 1:100 000, 2016 г.

**Графическое описание границы между субъектами Российской Федерации – Республикой Татарстан и Ульяновской областью**

Лист 21




**Масштаб 1:25 000**


Используемые условные знаки и обозначения:

- ● 45 – поворотная точка границы
- ——— – граница между Республикой Татарстан и Ульяновской областью
- —·—·— – граница между субъектами Российской Федерации по данным картографической основы*
- ——— – граница поселения

*Цифровые топографические карты открытого пользования ФГБУ «Центр геодезии, картографии и ИПД» М 1:25 000, 2016 г.

**Графическое описание границы между субъектами Российской Федерации – Республикой Татарстан и Ульяновской областью**

Лист 22




**Масштаб 1:25 000**

Используемые условные знаки и обозначения:

● 47 – поворотная точка границы

– граница между Республикой Татарстан и Ульяновской областью

– граница между субъектами Российской Федерации по данным картографической основы*


– граница поселения

*Цифровые топографические карты открытого пользования ФГБУ «Центр геодезии, картографии и ИПД» М 1:25 000, 2016 г.

**Графическое описание границы между субъектами Российской Федерации – Республикой Татарстан и Ульяновской областью**



Лист 23




**Масштаб 1:25 000**


Используемые условные знаки и обозначения:

- 49 – поворотная точка границы
- – граница между Республикой Татарстан и Ульяновской областью
- – граница между субъектами Российской Федерации по данным картографической основы*
- – граница поселения

*Цифровые топографические карты открытого пользования ФГБУ «Центр геодезии, картографии и ИПД» М 1:25 000, 2016 г.

## Графическое описание границы между субъектами Российской Федерации – Республикой Татарстан и Ульяновской областью

Лист 24




**Масштаб 1:25 000**

Используемые условные знаки и обозначения:


- ● 52 – поворотная точка границы
- – граница между Республикой Татарстан и Ульяновской областью
- – граница между субъектами Российской Федерации по данным картографической основы*
- – граница поселения

*Цифровые топографические карты открытого пользования ФГБУ «Центр геодезии, картографии и ИПД» М 1:25 000, 2016 г.

**Графическое описание границы между субъектами Российской Федерации – Республикой Татарстан и Ульяновской областью**



Лист 25




**Масштаб 1:25 000**

Используемые условные знаки и обозначения:

● 54 – поворотная точка границы

– граница между Республикой Татарстан и Ульяновской областью


– граница между субъектами Российской Федерации по данным картографической основы*

*Цифровые топографические карты открытого пользования ФГБУ «Центр геодезии, картографии и ИПД» М 1:25 000, 2016 г.

## Графическое описание границы между субъектами Российской Федерации – Республикой Татарстан и Ульяновской областью



Лист 26




**Масштаб 1:25 000**


Используемые условные знаки и обозначения:

- 56 – поворотная точка границы
- – граница между Республикой Татарстан и Ульяновской областью
- 7 – номер лесного квартала
- – граница между субъектами Российской Федерации по данным картографической основы*
- – граница поселения

*Цифровые топографические карты открытого пользования ФГБУ «Центр геодезии, картографии и ИПД» М 1:25 000, 2016 г.

**Графическое описание границы между субъектами Российской Федерации –
Республикой Татарстан и Ульяновской областью**

Лист 27




**Масштаб 1:25 000**


Используемые условные знаки и обозначения:

- ● 57 – поворотная точка границы
- (красная линия) – граница между Республикой Татарстан и Ульяновской областью
- *39* – номер лесного квартала
- (штрихпунктирная линия) – граница между субъектами Российской Федерации по данным картографической основы*
- (фиолетовая линия) – граница поселения

*Цифровые топографические карты открытого пользования ФГБУ «Центр геодезии, картографии и ИПД» М 1:25 000, 2016 г.

**Графическое описание границы между субъектами Российской Федерации –
Республикой Татарстан и Ульяновской областью**

Лист 28




**Масштаб 1:25 000**

Используемые условные знаки и обозначения:

● 60 – поворотная точка границы

– граница между Республикой Татарстан и Ульяновской областью


– граница между субъектами Российской Федерации по данным картографической основы*

– граница поселения

*Цифровые топографические карты открытого пользования ФГБУ «Центр геодезии, картографии и ИПД» М 1:25 000, 2016 г.

**Графическое описание границы между субъектами Российской Федерации – Республикой Татарстан и Ульяновской областью**

Лист 29




**Масштаб 1:25 000**


Используемые условные знаки и обозначения:

- 62 – поворотная точка границы
- – граница между Республикой Татарстан и Ульяновской областью
- *43* – номер лесного квартала
- – граница между субъектами Российской Федерации по данным картографической основы*
- – граница поселения

*Цифровые топографические карты открытого пользования ФГБУ «Центр геодезии, картографии и ИПД» М 1:25 000, 2016 г.

## Графическое описание границы между субъектами Российской Федерации – Республикой Татарстан и Ульяновской областью

Лист 30




**Масштаб 1:25 000**


Используемые условные знаки и обозначения:

- ● 64 – поворотная точка границы
- ——— – граница между Республикой Татарстан и Ульяновской областью
- 2 – номер лесного квартала
- –·–·– – граница между субъектами Российской Федерации по данным картографической основы*
- –·–·– – граница муниципального района

*Цифровые топографические карты открытого пользования ФГБУ «Центр геодезии, картографии и ИПД» М 1:25 000, 2016 г.

**Графическое описание границы между субъектами Российской Федерации – Республикой Татарстан и Ульяновской областью**

Лист 31




**Масштаб 1:25 000**


Используемые условные знаки и обозначения:

- 65 – поворотная точка границы
- – граница между Республикой Татарстан и Ульяновской областью
- *149* – номер лесного квартала
- – граница между субъектами Российской Федерации по данным картографической основы*
- – граница муниципального района
- – граница поселения

*Цифровые топографические карты открытого пользования ФГБУ «Центр геодезии, картографии и ИПД» М 1:25 000, 2016 г.

**Графическое описание границы между субъектами Российской Федерации – Республикой Татарстан и Ульяновской областью**

Лист 32




**Масштаб 1:25 000**

Используемые условные знаки и обозначения:


- 67 – поворотная точка границы
- – граница между Республикой Татарстан и Ульяновской областью
- *160* – номер лесного квартала
- – граница между субъектами Российской Федерации по данным картографической основы*
- – граница поселения

*Цифровые топографические карты открытого пользования ФГБУ «Центр геодезии, картографии и ИПД» М 1:25 000, 2016 г.

**Графическое описание границы между субъектами Российской Федерации – Республикой Татарстан и Ульяновской областью**



Лист 33




**Масштаб 1:25 000**

Используемые условные знаки и обозначения:

- ● 70 – поворотная точка границы
- ——— – граница между Республикой Татарстан и Ульяновской областью
- *134* – номер лесного квартала
- – · · – · · – граница между субъектами Российской Федерации по данным картографической основы*
- – · – · – граница муниципального района

*Цифровые топографические карты открытого пользования ФГБУ «Центр геодезии, картографии и ИПД» М 1:25 000, 2016 г.

Россия Федерациясе субъектлары –
Татарстан Республикасы һәм
Ульяновск өлкәсе арасындагы
чик урнашкан урынны билгеләү турында
2022 елның 4 октябрендәге 52/10-Д номерлы
килешүгә
2 нче кушымта

**РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ СУБЪЕКТЛАРЫ – ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҺӘМ УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕ АРАСЫНДАГЫ ЧИКНЕҢ ТЕКСТЛЫ ТАСВИРЛАМАСЫ**

Россия Федерациясе субъектлары – Татарстан Республикасы һәм Ульяновск өлкәсе арасындагы чикнең әлеге текстлы тасвирламасында Россия Федерациясе субъектлары – Татарстан Республикасы һәм Ульяновск өлкәсе арасындагы чикнең график тасвирламасында күрсәтелгән чикнең борылыш нокталарының шартлы билгеләре (номерлары) файдаланыла.

Татарстан Республикасы һәм Ульяновск өлкәсе арасында чик Ульяновск өлкәсе, Татарстан Республикасы һәм Чуваш Республикасы арасындагы чикләрнең тоташу (уртак) ноктасы булган 1 нче ноктадан уза. Тоташу ноктасы Чуваш Республикасы Шомырша урманчылыгының Чукалы участок урманчылыгындагы 133 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чигендә урнашкан.

1 нче ноктадан 2 нче ноктага кадәр чик гомуми көнчыгыш юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,27 км уза.

Татарстан Республикасы һәм Ульяновск өлкәсе арасында чикнең беренче участогы Ульяновск өлкәсе, Татарстан Республикасы һәм Чуваш Республикасы арасындагы чикләрнең тоташу (уртак) ноктасы булган 2 нче ноктада тәмамлана. Чикләрнең тоташу ноктасы Чуваш Республикасы Шомырша районы Яблоновка авылының төньяк-көнбатыш чигеннән көнбатышка таба якынча 1,64 км ераклыкта чокырның төньяк-көнбатыш ярында урнашкан.

Татарстан Республикасы һәм Ульяновск өлкәсе арасында чикнең икенче участогы Ульяновск өлкәсе, Татарстан Республикасы һәм Чуваш Республикасы арасындагы чикләрнең тоташу (уртак) ноктасы булган 3 нче ноктадан уза. Чикләрнең тоташу ноктасы Ульяновск өлкәсе Сурск урманчылыгының Астрадамовка участок урманчылыгындагы 53 нче урман кварталының көнчыгыш чигендә урнашкан.

3 нче ноктадан 4 нче ноктага кадәр чик көньяк-көнбатыш юнәлештә Ульяновск өлкәсе Сурск урманчылыгының Астрадамовка участок урманчылыгындагы 53 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 0,28 км уза, алга таба Татарстан Республикасы Буа урманчылыгының Чүпрәле участок урманчылыгындагы 42 нче урман кварталы һәм Ульяновск өлкәсе Сурск урманчылыгының Астрадамовка участок урманчылыгындагы 53 нче урман кварталы арасында урман ызаны буйлап 1,09 км уза.

Татарстан Республикасы һәм Ульяновск өлкәсе арасындагы чикнең икенче участогы Ульяновск өлкәсе, Татарстан Республикасы һәм Чуваш Республикасы арасындагы чикләрнең тоташу (уртак) ноктасы булган 4 нче ноктада тәмамлана. Чикләрнең тоташу ноктасы Ульяновск өлкәсе Сурск урманчылыгының Астрадамовка участок урманчылыгындагы 52 нче, 53 нче урман кварталлары һәм Татарстан Республикасы Буа урманчылыгының Чүпрәле участок урманчылыгындагы 42 нче урман кварталы чиге кисешкән урын янында урнашкан.

Татарстан Республикасы һәм Ульяновск өлкәсе арасындагы чикнең өченче участогы Ульяновск өлкәсе, Татарстан Республикасы һәм Чуваш Республикасы арасындагы чикләрнең тоташу (уртак) ноктасы булган 5 нче ноктадан уза. Чикләрнең тоташу ноктасы кыр ышыклау урман полосасының көнбатыш ягында Татарстан Республикасы Чүпрәле районы Иске Чәке авылының төньяк-көнбатыш чигеннән көнбатышка таба якынча 2,78 км ераклыкта урнашкан.

5 нче ноктадан 6 нчы ноктага кадәр чик көньяк юнәлештә урман полосасының көнчыгыш ягы һәм авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,54 км уза.

6 нчы ноктадан 7 нче ноктага кадәр чик көньяк-көнбатыш юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 0,15 км уза, алга таба кибеп бара торган инеш уртасыннан агым уңаена түбәнгә Гремячий Ключ инешенә кадәр 0,53 км уза, аннары көньяк-көнчыгыш юнәлештә Гремячий Ключ инеше уртасыннан агым уңаена түбәнгә 1,29 км бара.

7 нче ноктадан 8 нче ноктага кадәр чик көньяк-көнбатыш юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 0,29 км, алга таба көньяк юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 0,05 км, аннары урман полосасының көнбатыш ягы буйлап 0,66 км, аннары, Татарстан Республикасы Чүпрәле районы Татар Шатрашаны авылы һәм Ульяновск өлкәсе Сурск районының Шатрашан авылы арасындагы автомобиль юлын һәм Олы Яклы елгасын кисеп үтеп, Татарстан Республикасы Чүпрәле районы Татар Шатрашаны авылының көнбатыш чиге буенча авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,17 км уза.

8 нче ноктадан 9 нчы ноктага кадәр чик көньяк юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 0,84 км, алга таба урман полосасының көнчыгыш ягы буенча 3,16 км, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,54 км, алга таба урман полосасының көнчыгыш ягы буенча 0,71 км, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 0,18 км уза.

9 нчы ноктадан 10 нчы ноктага кадәр чик көнчыгыш юнәлештә, Руссалимка елгасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,20 км, алга таба урман полосасының төньяк ягы буйлап 0,62 км уза.

10 нчы ноктадан 11 нче ноктага кадәр чик, Руссалимка елгасын кисеп үтеп, төньяк-көнбатыш юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,21 км уза, аннары урман полосасының көньяк-көнбатыш ягы буйлап 1,49 км, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 0,94 км, аннары төньяк-көнчыгыш юнәлештә 1,05 км һәм көньяк-көнчыгыш юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 0,5 км уза.

11 нче ноктадан 12 нче ноктага кадәр чик гомуми төньяк-көнчыгыш юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Олы Яклы елгасына кадәр 3,61 км уза.

12 нче ноктадан 13 нче ноктага кадәр чик гомуми төньяк-көнчыгыш юнәлештә Олы Яклы елгасының уртасыннан агымга каршы өскә таба 1,32 км, алга таба көньяк-көнчыгыш юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,21 км, аннары Маклавыш елгасының уртасыннан агымга каршы өскә таба көньяк-көнчыгыш һәм көньяк юнәлешләрдә 3,20 км уза.

13 нче ноктадан 14 нче ноктага кадәр чик төньяк-көнчыгыш юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап урман кырыена кадәр 0,62 км уза, алга таба Татарстан Республикасы Буа урманчылыгының Чүпрәле участок урманчылыгындагы 44 нче урман кварталы һәм Ульяновск өлкәсе Майна урманчылыгының участок урманчылыгындагы 105 нче урман кварталы арасындагы урман ызаны буенча 0,99 км уза.

14 нче ноктадан 15 нче ноктага кадәр чик көньяк-көнчыгыш юнәлештә Ульяновск өлкәсе Майна урманчылыгының участок урманчылыгындагы 105 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 0,35 км, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,81 км, аннары урман массивының төньяк-көнчыгыш ягы буйлап 0,06 км, алга таба көнчыгыш юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,82 км уза.

15 нче ноктадан 16 нчы ноктага кадәр чик төньяк-көнчыгыш юнәлештә, кибеп бара торган инешне кисеп үтеп, урман полосасының төньяк-көнбатыш ягы һәм авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,34 км уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба Ульяновск өлкәсе Майна урманчылыгының участок урманчылыгындагы 109 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 0,56 км, алга таба урман полосасының төньяк-көнбатыш ягы буйлап 0,61 км, аннары Ульяновск өлкәсе Майна урманчылыгының участок урманчылыгындагы 108 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 0,25 км, алга таба урман полосасының төньяк-көнбатыш ягы буйлап 0,70 км уза.

16 нчы ноктадан 17 нче ноктага кадәр чик төньяк-көнчыгыш юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 0,17 км, аннары урман полосасының төньяк-көнбатыш ягы буйлап 1,93 км, алга

таба, Чынлы елгасының чишмә башын кисеп үтеп, төньяк юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 0,80 км уза.

17 нче ноктадан 18 нче ноктага кадәр чик, Чуваш Елгасы инешен кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатыш юнәлештә 2,89 км уза.

18 нче ноктадан 19 нчы ноктага кадәр чик төньяк-көнчыгыш юнәлештә урман полосасының көньяк-көнчыгыш ягы буйлап 2,62 км, алга таба урман полосасының төньяк-көнбатыш ягы буйлап 1,12 км, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,98 км уза, алга таба урман полосасының төньяк-көнбатыш ягы буйлап 0,80 км, аннары, исемсез инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 0,83 км уза.

19 нчы ноктадан 20 нче ноктага кадәр чик төньяк-көнбатыш юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 0,66 км уза, алга таба урман полосасының көньяк-көнбатыш ягы буйлап 1,61 км уза.

20 нче ноктадан 21 нче ноктага кадәр чик төньяк-көнчыгыш юнәлештә, кибеп бара торган инешне һәм Елга елгасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 4,79 км уза.

21 нче ноктадан 22 нче ноктага кадәр чик төньяк-көнбатыш юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,16 км, алга таба, А-151 Цивильск – Ульяновск автомобиль юлын һәм исемсез инешне кисеп үтеп, төньяк-көнчыгыш юнәлештә 2,39 км уза.

22 нче ноктадан 23 нче ноктага кадәр чик көнчыгыш юнәлештә, исемсез инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,04 км уза, алга таба урман полосасы фрагментларының көньяк ягы буйлап 1,60 км, аннары ике рәтле урман полосасының көньяк фрагментының төньяк ягы буйлап 0,57 км уза һәм алга таба урман полосасының көньяк ягы буенча 1,75 км, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 0,85 км уза.

23 нче ноктадан 24 нче ноктага кадәр чик көньяк-көнчыгыш юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 0,87 км, алга таба урман полосасының төньяк-көнчыгыш ягы буйлап 1,59 км, аннары, исемсез инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,41 км, алга таба элеккеге колхоз бакчасының көнбатыш ягыннан 0,46 км, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Чынлы елгасына кадәр 0,06 км уза.

24 нче ноктадан 25 нче ноктага кадәр чик көнбатыш юнәлештә Чынлы елгасының уртасыннан агымга каршы өскә таба 5,38 км уза.

25 нче ноктадан 26 нчы ноктага кадәр чик көньяк-көнчыгыш юнәлештә, Татарстан Республикасы Чүпрәле районының Зур Чынлы авылына бара торган автомобиль юлын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 0,52 км, алга таба урман полосасының көньяк-көнбатыш ягы буйлап 0,98 км уза, аннары, кибеп бара торган инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 0,70 км, алга таба урман полосасының көньяк-көнбатыш ягы буйлап 0,23 км, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 3,08 км уза.

26 нчы ноктадан 27 нче ноктага кадәр чик көнчыгыш юнәлештә урман полосасының төньяк ягы буйлап 0,64 км, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,41 км уза, аннары урман полосасының көньяк ягы буенча 4,02 км, алга таба көньяк-көнчыгыш юнәлештә урман полосасының төньяк-көнчыгыш ягы буйлап 0,86 км, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Бөгернә елгасына кадәр 0,48 км уза.

27 нче ноктадан 28 нче ноктага кадәр чик төньяк-көнчыгыш юнәлештә Бөгернә елгасының уртасыннан агым уңаена түбәнгә 0,60 км уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньякка 0,23 км, аннары урман полосасының көнбатыш ягы буйлап 2,79 км уза.

28 нче ноктадан 29 нчы ноктага кадәр чик көнбатыш юнәлештә урман полосасының көньяк ягы буйлап 1,18 км, алга таба төньяк юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 0,15 км уза, аннары урман полосасының көнбатыш ягы буйлап 2,61 км, алга таба, кибеп бара торган инешне кисеп үтеп, Чынлы елгасына кадәр авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 0,54 км уза.

29 нчы ноктадан 30 нчы ноктага кадәр чик көнчыгыш юнәлештә Чынлы елгасының уртасыннан агым уңаена түбәнгә 1,81 км, алга таба төньяк-көнбатыш юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,37 км, аннары төньяк-көнчыгыш юнәлештә урман полосасының көньяк-көнчыгыш ягы буйлап 1,77 км уза.

30 нчы ноктадан 31 нче ноктага кадәр чик көньяк-көнчыгыш юнәлештә, Чынлы елгасының иске үзәнен һәм мелиорация канавын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,72 км, алга таба төньяк-көнчыгышка таба мелиорация канавының көньяк-көнчыгыш ягы буенча 4,57 км уза.

31 нче ноктадан 32 нче ноктага кадәр чик көньяк-көнчыгыш юнәлештә, Иске Чынлы елгасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 0,24 км уза, алга таба урман полосасының көньяк-көнбатыш ягы буйлап 2,63 км, аннары төньяк-көнчыгыш юнәлештә урман полосасының көньяк-көнчыгыш ягы буйлап 0,87 км, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,34 км, аннары урман полосасының көньяк-көнчыгыш ягы буйлап 0,73 км уза.

32 нче ноктадан 33 нче ноктага кадәр чик төньяк юнәлештә урман полосасының көнбатыш ягы буйлап 2,07 км, алга таба, Чынлы елгасын, Кече Чынлы елгасын һәм исемсез инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 0,94 км уза, аннары урман полосасының көнбатыш ягы буйлап 1,29 км, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,34 км уза.

33 нче ноктадан 34 нче ноктага кадәр чик көнчыгыш юнәлештә урман полосасының көньяк ягы буйлап 2,14 км, алга таба көньяк юнәлештә урман полосасының көнчыгыш ягы буйлап 3,14 км Кече Чынлы елгасына кадәр уза.

34 нче ноктадан 35 нче ноктага кадәр чик гомуми көньяк-көнчыгыш юнәлештә Кече Чынлы елгасының уртасыннан агым уңаена түбәнгә 3,79 км, алга таба көньяк-көнбатыш һәм көньяк-көнчыгыш юнәлештә инеш буйлап агымга каршы өскә таба һәм буа буйлап 0,55 км, аннары көньяк-көнбатыш юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 0,21 км уза, алга таба гомуми төньяк-көнчыгыш юнәлештә Чынлы елгасының уртасыннан агым уңаена түбәнгә 1,54 км, аннары, Р-241 Казан – Ульяновск автомобиль юлын һәм Казан – Ульяновск тимер юлын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,19 км уза, алга таба исемсез инешнең уртасыннан агым уңаена түбәнгә Чынлы елгасына кадәр 2,01 км, аннары гомуми көнчыгыш юнәлештә Чынлы елгасының уртасыннан агым уңаена түбәнгә 1,07 км уза.

35 нче ноктадан 36 нчы ноктага кадәр чик, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатыш юнәлештә 1,44 км уза, алга таба көньяк-көнчыгыш юнәлештә 2,55 км, аннары төньяк-көнчыгыш юнәлештә 0,79 км, алга таба көньяк-көнчыгыш юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 0,16 км уза, аннары көньяк-көнчыгыш юнәлештә урман полосасының көньяк-көнбатыш ягы буйлап 0,64 км, алга таба төньяк-көнчыгыш юнәлештә урман полосасының көньяк-көнчыгыш ягы буйлап 0,76 км, аннары көньяк-көнчыгыш юнәлештә урман полосасының көньяк-көнбатыш ягы буйлап 0,17 км, алга таба төньяк-көнчыгыш юнәлештә чокыр уртасыннан 0,61 км, аннары көньяк-көнчыгыш юнәлештә 0,24 км Зөя елгасы уртасына кадәр уза.

36 нчы ноктадан 37 нче ноктага кадәр чик көньяк-көнбатыш юнәлештә Зөя елгасының уртасыннан агымга каршы өскә таба 7,23 км уза.

37 нче ноктадан 38 нче ноктага кадәр чик көньяк-көнчыгыш юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,36 км, алга таба урман полосасының төньяк-көнчыгыш ягы буйлап 3,36 км уза.

38 нче ноктадан 39 нчы ноктага кадәр чик төньяк-көнчыгыш юнәлештә, Ульяновск өлкәсе Ульяновск районының Рус Бидәңгесе авылын һәм Татарстан Республикасы Тәтеш районының Сөендек авылын тоташтыручы автомобиль юлын кисеп үтеп, урман полосасының төньяк-көнбатыш ягы буйлап 2,98 км, алга таба урман полосасының төньяк-көнбатыш ягы буйлап 2,56 км, аннары көньяк-көнчыгыш юнәлештә урман полосасының көньяк-көнбатыш ягы буйлап 1,96 км кибеп бара торган инешкә кадәр уза.

39 нчы ноктадан 40 нчы ноктага кадәр чик төньяк-көнчыгыш юнәлештә кибеп бара торган инешнең уртасыннан агым уңаена түбәнгә Бидәңге елгасына кушылган урынга кадәр 0,17 км, алга таба көньяк юнәлештә Бидәңге елгасының уртасыннан агымга каршы өскә таба 3,28 км уза.

40 нчы ноктадан 41 нче ноктага кадәр чик көньяк-көнчыгыш юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 0,16 км, аннары урман полосасының көньяк-көнбатыш ягы буйлап 2,51 км, алга таба, Ульяновск өлкәсе Ульяновск районының Ундоры авылына бара торган автомобиль юлын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 0,08 км, аннары Татарстан Республикасы Тәтеш урманчылыгының Тархан участок урманчылыгындагы 32 нче, 33 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чикләре буйлап 1,68 км уза.

41 нче ноктадан 42 нче ноктага кадәр чик көньяк-көнчыгыш юнәлештә Татарстан Республикасы Тәтеш урманчылыгының Тархан участок урманчылыгындагы 33, 53, 62 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чикләре буйлап 1,70 км, алга таба Татарстан Республикасы Тәтеш урманчылыгының Тархан участок урманчылыгындагы 62 нче, 66 нчы урман кварталлары һәм Ульяновск өлкәсе Ульяновск районының Ундоры урманчылыгындагы 1, 2, 3 нче урман кварталлары арасындагы урман ызаны буйлап 2,58 км, аннары Идел елгасы акваториясе (Куйбышев сусаклагычы) буйлап 0,16 км уза.

42 нче ноктадан 43 нче ноктага кадәр чик көнчыгыш юнәлештә Идел елгасы акваториясе (Куйбышев сусаклагычы) буйлап 26,99 км уза.

43 нче ноктадан 44 нче ноктага кадәр чик төньяк юнәлештә Идел елгасы акваториясе (Куйбышев сусаклагычы) буйлап 19,01 км уза.

44 нче ноктадан 45 нче ноктага кадәр чик көнчыгыш юнәлештә Идел елгасы акваториясе (Куйбышев сусаклагычы) буйлап 8,82 км уза.

45 нче ноктадан 46 нчы ноктага кадәр чик гомуми көнчыгыш юнәлештә борылмалы сызык рәвешендә Үтәк елгасы тамагы култыгының уртасы буйлап Ульяновск өлкәсе Иске Майна урманчылыгының Жедяевка участок урманчылыгындагы 1 нче урман кварталы чигенә кадәр 11,09 км уза.

46 нчы ноктадан 47 нче ноктага кадәр чик төньяк-көнчыгыш юнәлештә Ульяновск өлкәсе Иске Майна урманчылыгының Жедяевка участок урманчылыгындагы 1 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 0,47 км, алга таба Татарстан Республикасы Болгар урманчылыгының Спас участок урманчылыгындагы 67 нче урман кварталының аерымланган кисәкләренең көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап 0,70 км, аннары Татарстан Республикасы Спас районының Танкеевка авылына бара торган автомобиль юлына кадәр авыл хуҗалыгы җирләре буенча 0,41 км уза, алга таба әлеге автомобиль юлының көнбатыш ягы буйлап 0,16 км, аннары, әлеге автомобиль юлын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 3,99 км уза.

47 нче ноктадан 48 нче ноктага кадәр чик төньяк-көнчыгыш юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,39 км, алга таба көнчыгыш юнәлештә урман полосасының көньяк ягы буйлап 1,28 км, аннары көньяк-көнчыгыш юнәлештә урман полосасының көньяк-көнбатыш ягы буйлап 0,97 км, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,97 км уза.

48 нче ноктадан 49 нчы ноктага кадәр чик төньяк-көнчыгыш юнәлештә куаклыклар полосасының көньяк-көнчыгыш ягы буйлап 2,61 км, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 0,48 км уза.

49 нчы ноктадан 50 нче ноктага кадәр чик төньяк-көнбатыш юнәлештә урман полосасының төньяк-көнчыгыш ягы буйлап 0,28 км, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,67 км уза.

50 нче ноктадан 51 нче ноктага кадәр чик төньяк-көнчыгыш юнәлештә урман полосасының өч фрагментының төньяк-көнбатыш ягы буйлап 2,73 км, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 0,41 км уза.

51 нче ноктадан 52 нче ноктага кадәр чик көньяк-көнчыгыш юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 0,31 км, аннары ике рәтле урман полосалары арасында 0,40 км, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 6,64 км уза.

52 нче ноктадан 53 нче ноктага кадәр чик көнчыгыш юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 0,87 км, алга таба урман полосасының көньяк ягы буйлап 0,32 км, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,90 км, алга таба көньяк юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 0,95 км, аннары көнбатыш юнәлештә Конопляное күленең көньяк яры буйлап авыл хуҗалыгы җирләре буенча 1,95 км уза.

53 нче ноктадан 54 нче ноктага кадәр чик көньяк-көнчыгыш юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,38 км, алга таба урман полосасының төньяк-көнчыгыш ягы буйлап 3,07 км уза.

54 нче ноктадан 55 нче ноктага кадәр чик көньяк-көнчыгыш юнәлештә, исемсез күлләрне, чокырларны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,94 км уза.

55 нче ноктадан 56 нчы ноктага кадәр чик көньяк юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 5,35 км уза.

56 нчы ноктадан 57 нче ноктага кадәр чик көньяк-көнчыгыш юнәлештә Ульяновск өлкәсе Иске Майна урманчылыгының Йорткүл участок урманчылыгындагы 7, 8, 10 нчы урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап 2,81 км уза.

57 нче ноктадан 58 нче ноктага кадәр чик гомуми көньяк-көнбатыш юнәлештә Ульяновск өлкәсе Иске Майна урманчылыгының Йорткүл участок урманчылыгындагы 10 нчы урман кварталының көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап 1,73 км, алга таба Татарстан Республикасы Әлки урманчылыгының Чернореченск участок урманчылыгындагы 15, 16, 19 нчы урман кварталлары һәм Ульяновск өлкәсе Иске Майна урманчылыгының Йорткүл участок урманчылыгындагы 20 нче, 29 нчы урман кварталлары арасындагы чик буйлап 2,70 км уза, аннары Ульяновск өлкәсе Иске Майна урманчылыгының Йорткүл участок урманчылыгындагы 39 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап Үтәк елгасы уртасына кадәр 1,11 км уза.

58 нче ноктадан 59 нчы ноктага кадәр чик көнчыгыш юнәлештә Үтәк елгасы уртасыннан агымга каршы өскә таба 5,29 км, алга таба көньяк-көнчыгыш юнәлештә Ульяновск өлкәсе Иске Майна урманчылыгының Йорткүл участок урманчылыгындагы 51 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 0,28 км уза.

59 нчы ноктадан 60 нчы ноктага кадәр чик көнбатыш юнәлештә Ульяновск өлкәсе Иске Майна урманчылыгының Йорткүл участок урманчылыгындагы 51 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 0,60 км, алга таба гомуми көньяк-көнчыгыш юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,96 км уза.

60 нчы ноктадан 61 нче ноктага кадәр чик көньяк-көнбатыш юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 3,53 км уза.

61 нче ноктадан 62 нче ноктага кадәр чик көньяк юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,45 км, алга таба урман массивының көнчыгыш ягы буенча 0,36 км, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 0,12 км кибеп бара торган инешкә кадәр уза.

62 нче ноктадан 63 нче ноктага кадәр чик көньяк-көнчыгыш юнәлештә кибеп бара торган инеш буйлап агымга каршы өскә таба 3,90 км уза.

63 нче ноктадан 64 нче ноктага кадәр чик көньяк юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 0,96 км, алга таба урман полосасының көнбатыш ягы буйлап 1,0 км, аннары көньяк-көнбатыш юнәлештә кибеп бара торган инеш буйлап агым уңаена түбәнгә Майна елгасы уртасына кадәр 3,82 км уза.

64 нче ноктадан 65 нче ноктага кадәр чик гомуми көнчыгыш юнәлештә, 16К-1477 Ким – Кузнечиха – Лесная Хмелевка автомобиль юлын кисеп үтеп, Майна елгасы уртасыннан агымга каршы өскә таба 13,71 км уза.

65 нче ноктадан 66 нчы ноктага кадәр чик көнчыгыш юнәлештә Кече Майна елгасы уртасыннан агымга каршы өскә таба 3,60 км, алга таба көньяк-көнчыгыш юнәлештә Майна Башы елгасы уртасыннан агымга каршы өскә таба 0,76 км, алга таба, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,92 км Татарстан Республикасы Әлки урманчылыгының Юхмачы участок урманчылыгындагы 140 нчы урман кварталы чигенә кадәр уза.

66 нчы ноктадан 67 нче ноктага кадәр чик көньяк-көнбатыш юнәлештә Татарстан Республикасы Әлки урманчылыгының Юхмачы участок урманчылыгындагы 140 нчы, 148 нче урман кварталлары төньяк-көнбатыш чиге буйлап 0,37 км, алга таба көньяк-көнчыгыш юнәлештә Татарстан Республикасы Әлки урманчылыгының Юхмачы участок урманчылыгындагы 148, 149, 150, 156 нчы урман кварталлары һәм Ульяновск өлкәсе Яңа Чирмешән урманчылыгының Аппак участок урманчылыгындагы 10, 11, 12, 13, 14 нче урман кварталлары арасындагы урман ызаны буйлап 5,12 км, аннары көнчыгыш юнәлештә Татарстан Республикасы Әлки урманчылыгының Юхмачы участок урманчылыгындагы 156 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап инеш уртасына кадәр 0,56 км уза.

67 нче ноктадан 68 нче ноктага кадәр чик көньяк-көнчыгыш юнәлештә инеш уртасыннан агым уңаена түбәнгә Татарстан Республикасы Әлки урманчылыгы Юхмачы участок урманчылыгындагы 156, 159, 160 нчы урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,85 км уза.

68 нче ноктадан 69 нчы ноктага кадәр чик көнчыгыш юнәлештә Татарстан Республикасы Әлки урманчылыгының Юхмачы участок урманчылыгындагы 160 нчы һәм 161 нче урман кварталлары көньяк чиге буйлап 1,93 км, алга таба, чокырларны кисеп үтеп, урман полосасының көньяк ягы буйлап 2,10 км, аннары, чокырны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,49 км, алга таба урман полосасының көньяк ягы буйлап 0,52 км уза.

69 нчы ноктадан 70 нче ноктага кадәр чик көньяк-көнчыгыш юнәлештә урман утыртмасы буйлап 0,36 км, алга таба, Путак елгасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 0,52 км, аннары, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Аппак авылына бара торган автомобиль юлын кисеп үтеп, Ульяновск өлкәсе Мәләкәс районының Аппак авылына бара торган автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 0,79 км, алга таба көньяк юнәлештә Ульяновск өлкәсе Яңа Чирмешән урманчылыгының Аппак участок урманчылыгындагы 58 нче урман кварталы чигенә кадәр авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,50 км, аннары көньяк-көнчыгыш юнәлештә Ульяновск өлкәсе Яңа Чирмешән урманчылыгының Аппак участок урманчылыгындагы 58 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,29 км уза.

70 нче ноктадан 71 нче ноктага кадәр чик төньяк-көнчыгыш юнәлештә урман полосасының төньяк-көнбатыш ягы буйлап 1,14 км, алга таба Татарстан Республикасы Әлки урманчылыгының Юхмачы участок урманчылыгындагы 10 нчы урман кварталы һәм Ульяновск өлкәсе Яңа Чирмешән урманчылыгының Аппак участок урманчылыгындагы 88 нче урман кварталы арасындагы урман ызаны буйлап 1,28 км уза.

71 нче ноктадан 72 нче ноктага кадәр чик көньяк-көнчыгыш юнәлештә Ульяновск өлкәсе Яңа Чирмешән урманчылыгының Аппак участок урманчылыгындагы 88 нче, 89 нчы урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,77 км, алга таба көнчыгыш юнәлештә Чирмешән елгасы уртасыннан агымга каршы өскә таба 0,18 км, аннары көньяк-көнчыгыш юнәлештә Ульяновск өлкәсе Яңа Чирмешән урманчылыгының Салаван участок урманчылыгындагы 3 нче урман кварталы чиге буйлап 0,40 км, алга таба көнчыгыш юнәлештә Татарстан Республикасы Нурлат урманчылыгының Тумба участок урманчылыгындагы 133, 134, 135, 136, 125, 137 нче урман кварталлары һәм Ульяновск өлкәсе Яңа Чирмешән урманчылыгының Салаван участок урманчылыгындагы 3, 4, 5 нче урман кварталлары арасындагы урман ызаны буйлап 5,37 км уза.

Татарстан Республикасы һәм Ульяновск өлкәсе арасында чик Татарстан Республикасы Нурлат урманчылыгының Тумба участок урманчылыгындагы 137 нче урман кварталының көньягында һәм Ульяновск өлкәсе Яңа Чирмешән урманчылыгының Салаван участок урманчылыгындагы 5 нче урман кварталының төньяк-көнчыгышында, Петровский аймагының төньягындагы таш түшәлмәгән юл буенча Кече Чирмешән елгасыннан 5,5 км көнчыгыштарак урнашкан Татарстан Республикасы, Ульяновск өлкәсе һәм Самара өлкәләренең тоташу (уртак) ноктасы булган 72 нче ноктада тәмамлана.